| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ФЕДОТОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ФЕДОТОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2023 елның 28 апреленнән №16

«Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 14 мартындагы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 8 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча белән тулыландырырга:

«11) аның чит ил агенты статусын алуы.»;

8.4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«8.4. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенең гомуми принципларын үтәүләрен тәэмин итү һәм җирле үзидарә органында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу өчен муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы һәм муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу буенча комиссияләр төзелергә мөмкин.»;.»;

9.1 пунктының 3 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) « сүзләренә алмаштырырга;

10.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) муниципаль хезмәткәрләрнең чит ил агенты статусын алулары.».

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет ур., 6, Совет ур., 8 (мәдәният йорты бинасы), Кузьминовка авылы, Кооператив ур., 10 (СК бинасы), адреслары буенча урнашкан махсус

җиһазландырылган мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Федотовка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе В.И.Павлова